| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ШАРЛИАРЕМИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ<br>ПОСЕЛЕНИЕ САРМАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САРМАН МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ ШӘРЛӘРӘМӘ АВЫЛ<br>ЖИРЛЕГЕ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 6** **24.11.2025 ел**

**2020 елның 16 мартындагы 126 номерлы «Җир салымы турында» карарга үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законын 14нче статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Шәрләрәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Шәрләрәмә авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Советының «җир салымы турында» 2020 елның 16 мартындагы 126 номерлы карарына (Советның 12.12.2020 ел, № 9, 22.02.2023 ел, № 67, 07.11.2023 ел, № 83, 07.02.2025 ел, № 114, 20.10.2025 ел № 5 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

   4 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4.2.2 пунктчасы өстәргә:

   4.2.2. күпфатирлы йортлар астында урнашкан җир кишәрлекләре өчен торак милекчеләре ширкәтләренә;

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында халыкка җиткерергә (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернетны мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Шәрләрәмә авыл җирлеге Советы рәисе: Хуҗина Н.Н.